ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘТНӘ МУНИЦИАЛЬ РАЙОНЫ
ТҮБӘН КӨЕК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

СОВЕТ НИЖНЕКУЮКСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АТНИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

422741 Республика Татарстан Атнинский район с. Нижний Куюк. Тел. 3-32-47

"29" гыйнвар 2018 ел

**Карар № 2**
**Түбән Көек авыл җирлегенең 2018 елга наркотикларга каршы чаралар планын раслау турында**

2010 елнын 9 июнендәге 690 номерлы Россия Федерациясе Президентының «2020 елга кадәр Россия Федерациясенең Дәүләт наркотикларга каршы сәясәте стратегиясен раслау турында" Указы нигезендә, авыл җирлегендә сәламәт яшәү рәвешен пропагандалауга һәм наркотик чаралар куллануны кисәтүгә юнәлдерелгән 2018 елга чаралар планы һәм авыл җирлеге Уставы нигезендә карар бирәм:

1. Түбән Көек авыл җирлегенең 2018 елга наркотикларга каршы чаралар планын расларга.
2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.
4. Әлеге карар рәсми рәвештә халыкка игълан ителгән көннән соң үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Түбән Көек авыл җирлеге башлыгы: Мөхәммәтгалиев Ф.Т.

Әтнә муниципаль районы Түбән Көек
авыл җирлеге башлыгының
2018 елның 29 гыйнварындагы
2 номерлы карары белән расланды

Түбән Көек авыл җирлегенең 2018 елга наркотикларга каршы чаралар планы

| № п/п | Башкарылучы чаралар | Башкару срогы | Үтәүчеләр |
|---|---|---|---|
| 1. Наркотикларны законсыз куллану һәм наркомания таралуны кисәтү | | | |
| 1.1 | Хокук саклау һәм сәламәтлек саклау органнары хезмәткәрләренең наркотикларны законсыз кулланунын хокукый һәм медицина аспектларын яктырту максатында мәктәп укучылары, авыл яшьләре белән очрашуларны системалы рәвештә уздыру. | Ел дәвамында | Авыл җирлеге администрациясе, Түбән Көек төп белем бирү мәктәбе Түбән Көек авылы РФ Эчке эшләр министрлыгының Әтнә районы буенча бүлеге (килешү буенча) |
| 1.2 | Яшьләр акцияләре үткәрү: «Наркотикларсыз тормыш» акциясе<br><br>Бөтендөнья сәламәтлек көненә багышланган Акция<br><br>«Без СПИД ка каршы» протест акциясе | май<br><br>июнь<br><br>декабрь | Түбән Көек төп белем бирү мәктәбе Югары Көек авыл клубы Түбән Көек авылы мәдәният йорты<br><br>Югары Көек авыл клубы Түбән Көек авылы мәдәният йорты<br><br>Югары Көек авыл клубы Түбән Көек авылы мәдәният йорты (килешү буенча) |
| 1.3 | Сәламәт яшәү рәвешен пропагандалауга юнәлдерелгән спорт ярышлары, турнирлар үткәрү | Ел дәвамында | Авыл җирлеге администрациясе, Түбән Көек башлангыч белем бирү мәктәбе – балалар бакчасы (килешү буенча) |
| 2. Наркотикларның законсыз әйләнешен кисәтү буенча чаралар | | | |
| 2.1 | Наркотиклы үсемлекләрнең законсыз чәчүлекләрен ачыклау буенча оператив-тикшерү чараларын уздыру, наркотик әзерләүчеләрне, аны йөртүчеләрне тоткарлау. | май-октябрь | РФ Эчке эшләр министрлыгының Әтнә районы буенча бүлеге (килешү буенча) |
| 2.2 | Авыл җирлеге территориясендә кыргый киндерне һәм законсыз | 2, 3 квартал | Авыл җирлеге администрациясе, |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | чәчүлекләрне ачыклау һәм юк итү буенча чараларны тормышка ашыру | | РФ Эчке эшләр министрлыгының Әтнә районы буенча бүлеге (килешү буенча) |
| 2.3 | Наркотик чаралар кулланучы затлар турында исәп-хисап мәгълүматларын тикшерүне системалы рәвештә гамәлгә ашыру | июнь-октябрь | РФ Эчке эшләр министрлыгының Әтнә районы буенча бүлеге Түбән Көек ФАПы, Югары Көек ФАПы (килешү буенча) |
| 2.4 | Наркотик матдәләр булган үсемлекләрне законсыз рәвештә үстерүгә, шулай ук җәмәгатьчелек арасында наркотиклар куллануга карата тискәре мөнәсәбәт булдыруга, административ һәм җинаять җаваплылыгын аңлату максатыннан Авыл җирлеге торак пунктларында яшәүчеләр белән аңлату эшләре, җыелышлар үткәрү. | Ел дәвамында | Авыл җирлеге администрациясе, РФ Эчке эшләр министрлыгының Әтнә районы буенча бүлеге (килешү буенча) |
| 2.5 | Авыл җирлеге территориясендә чит ил гражданнарының килүен исәпкә алу һәм контрольдә тоту. | апрель - май | Авыл җирлеге администрациясе, Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Әтнә районы буенча миграция пункты (килешү буенча) |
| 3.Наркотикларны медицинаныкы булмаган куллануга юл куйган затларны дәвалау, эшкә яраклылыгын торгызу һәм реабилитацияләү | | | |
| 3.1 | Наркотиклар, психотроп матдәләр кулланучы гражданнарны ачыклау | Ел дәвамында | РФ Эчке эшләр министрлыгының Әтнә районы буенча бүлеге, Түбән Көек ФАПы, Югары Көек ФАПы (килешү буенча) |
| 3.2 | Сәламәтлек саклау учреждениеләрендә наркотик һәм башка психотроп матдәләргә ирекле үтеп керүне булдырмау. | Ел дәвамында | Түбән Көек ФАПы Югары Көек ФАПы |

Авыл җирлеге башлыгы: Мөхәммәтгалиев Ф.Т.